**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Большенуркеевского сельского поселения Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районы**
**Зур Нөркәй авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 09 февраль № 2

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының
Зур Нөркәй авыл җирлеге территориясендә
кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү олкәсендә
координация яисә киңәшмә органнары төзү
тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Сарман районы прокуратурасының 2021 елның 10 декабрендәге 02-07-02/2021 номерлы протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация яисә киңәшмә органнары төзү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы сайтында (http// sarmanovo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Зур Нөркәй авыл җирлеге
Башкарма комитет рәисе Р.М.Гайсин

Татарстан Республикасы Сарман
муниципаль районының Зур Нөркәй
авыл җирлеге башкарма комитетының
2022 елның 09 феврале 2 номерлы
карары белән расланган

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация яисә киңәшмә органнары төзү
ТӘРТИБЕ

1. Гомуми нигезләмәләр

Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация яисә киңәшмә органнары (алга таба - координация органнары) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру буенча килешенгән гамәлләрне тәэмин итү максатларында төзелә.

Координация органнары, билгеле бер төр бурычларны хәл иткәндә яки конкрет чаралар үткәргәндә, җирле үзидарә органнары яисә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыручы коммерциячел булмаган оешмалар инициативасы буенча төзелергә мөмкин. Киңәшмә органнары советлар тарафыннан исемләнә һәм мәсьәләләрне алдан карау һәм алар буенча тәкъдим итү характерындагы тәкъдимнәрне әзерләү өчен төзелә.

Төзелә торган совет яки комиссия бер үк вакытта координация органы да, киңәшмә органы да булырга мөмкин.

Координация органы төзү турында кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мәнфәгатьләрен чагылдыручы коммерциячел булмаган оешмалар мөрәҗәгать иткән очракта, җирле үзидарә органнары бер ай дәвамында мондый коммерциячел булмаган оешмаларга кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Үз эшчәнлегендә координация органнары Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм

күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы законнарына, башка норматив хокукый документларга, шулай ук әлеге Тәртипкә таяна.

.

## 2. Координация яисә киңәшмә органнарының төп максатлары

Координация яисә киңәшмә органнары түбәндәге максатларда оештырыла:

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларының ролен күтәрү;

- җирле үзидарә органнарының кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү инфраструктурасын төзүче дәүләт хакимияте органнары һәм эшкуарлык субъектлары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар белән эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашыру;

- кече һәм урта эшкуарлык субъектларын кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә муниципаль сәясәтне эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга җәлеп итү;

- кече һәм урта эшкуарлык субъектларының проблемаларын тикшерү һәм гомумиләштерү, аларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау;

- иҗтимагый оешмаларны, эшкуарлар берләшмәләрен, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен гражданнарның эшмәкәрлек эшчәнлегенә хокукын гамәлгә ашыруга кагылышлы мәсьәләләр буенча фикер алышуга җәлеп итү һәм әлеге мәсьәләләр буенча рекомендацияләр әзерләү;

- кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә муниципаль сәясәтне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән инициативаларны тәкъдим итү һәм аларга ярдәм күрсәтү;

- кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүне җайга салучы муниципаль хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрү;

## 3. Координация яисә киңәшмә органнары составы

Координация яисә киңәшмә органнары составына җирле үзидарә органнары вәкилләре, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыручы

коммерциячел булмаган оешмалар вәкилләре, кече һәм урта бизнес вәкилләре, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре керә ала. Координация яисә киңәшмә органының персоналы һәм вәкаләтләре Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән раслана.

Координация яисә киңәшмә органы рәисе булып Зур Нөркәй авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе тора.

Координация яисә киңәшмә органы рәисе:

- Координация яисә киңәшмә органы утырышларының көн тәртибен формалаштыра; координация яисә киңәшмә органы эшен оештыра һәм аның утырышларында рәислек итә;

- координация яисә киңәшмә органы утырышлары беркетмәләрен раслый;

- координация яисә киңәшмә органы составын үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә;

- координация яисә киңәшмә органы эшчәнлеге һәм координация яисә киңәшмә органы карары турында мәгълүматны кызыксынган дәүләт хакимияте органнары һәм авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына, шулай ук башка кызыксынучы затларга җибәрә;

- Координация яисә киңәшмә органы эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка гамәлләрне гамәлгә ашыра.

Координация яисә киңәшмә органы рәисе урынбасары аның әгъзалары арасыннан бер елга координация яисә киңәшмә органы рәисе тәкъдиме буенча сайлана.

Координация яисә киңәшмә органы рәисе урынбасары координация һәм киңәшмә органы рәисе күрсәтмәсе буенча:

- Координация яисә киңәшмә органы утырышында әзерләүне оештыра һәм рәислек итә;

- дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм коммерцияле булмаган оешмаларда координация яисә киңәшмә органы тәкъдим итә.

Координация яисә киңәшмә органы секретаре (алга таба - секретарь) координация яисә киңәшмә орган төзелгән Зур Нөркәй авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән билгеләнә.

Секретарьгә координация яисә киңәшмә органы утырышларына материалларны туплау һәм җибәрү, алар башланганчы 5 көн кала, аның әгъзаларына утырышларның вакыты, урыны һәм көн тәртибе турында хәбәр итү, утырышлар беркетмәләрен алып бару, рәсмиләштерү һәм саклау өчен җаваплылык йөкләнә.

Координация яисә киңәшмә органы утырышлары ул раслаган эшчәнлек планы нигезендә, әмма ярты елга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Кирәк булган очракта, координация яисә киңәшмә органының өчтән бер әгъзасыннан да ким булмаган әгъзасы инициативасы буенча координация яисә киңәшмә органының чираттан тыш утырышы билгеләнергә мөмкин.

Координация яисә киңәшмә органы утырышы белән җитәкчелек итүне рәис башкара. Рәис булмаган очракта, утырышны аның урынбасары үткәрә.

Координация яисә киңәшмә органы утырышына дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, координация яисә киңәшмә органы составына керми торган вәкилләр чакырыла ала.

Координация яисә киңәшмә органы тәкъдимнәре кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы дәүләт хакимиятенең тиешле башкарма органнарына, җирле үзидарә органнарына җибәрелә.

4. Координация яисә киңәшмә органнары эшчәнлеген тәэмин итү

Координация яисә киңәшмә органы, әгәр аның утырышында аның әгъзаларының илле проценты катнашса, хокуклы була. Карала торган мәсьәлә буенча карар координация яисә киңәшмә органы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Координация яисә киңәшмә органы эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү, шул исәптән гомуми файдаланудагы мәгълүмат системаларында координация яисә киңәшмә орган төзү турында мәгълүмат урнаштыру, аның

утырышын уздыру датасы һәм урыны, көн тәртибе һәм карарлары турында мәгълүмат урнаштыру, Зур Нөркәй  авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла. Координация яисә киңәшмә органы эше регламенты аның утырышында раслана.